**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы**
**КАРАРЫ**

**2016 елның 14 декабре №73**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2016 елның 18 апрелендәге 36 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 30 июнендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 29 сентябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2016 елның 18 апрелендәге 36 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2) 8 статьяда: а) 1 һәм 3 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына, вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә, шулай ук яллаучы (эш бирүче) вәкиленең тиешле карары булганда - белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә.»

«3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типлаштырылган квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә: вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәүче төркемнәре өчен югары белем булу; вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - кимендә ике ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә биш ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы.

Өлкән һәм кече төркемнәрнең муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре билгеләнми.

Әлеге статья максатларында муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәрнең дәүләт граждан хезмәте Вазыйфаларында һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт Вазыйфаларында һәм федераль дәүләт хезмәте Вазыйфаларында башка төр хезмәт стажы исәпкә алына.»;

12 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункт өстәргә: «9.1) әлеге Нигезләмәнең 14.1 статьясында каралган белешмәләрне тапшырмау;»;

1.3. 3 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 14.1 статья өстәргә:

«14.1. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат урнаштыру турында белешмәләр тапшыру

1. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан, муниципаль хезмәткәр һәркем файдалана алырлык мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирүче күрсәткечләрне урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында белешмәләрне яллаучы вәкиленә түбәндәгеләр тапшыралар:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан - муниципаль хезмәткә кергән елдан алдагы өч календарь елда хезмәткә кергәндә;

2) муниципаль хезмәткәр - күрсәтелгән мәгълүматны тапшыру елыннан алдагы календарь ел өчен ел саен, муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын үтәү кысаларында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматны урнаштыру очракларыннан тыш.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр муниципаль хезмәткә кергәндә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан, ә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан - хисап елыннан соң килүче елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән рәвештә тапшырыла.

3. Эшкә алучының вәкиле карары буенча, вәкаләтле муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматны эшкәртә, шулай ук әлеге статьяның 1 өлешендә каралган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерә.»;

1.4. 15 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10.1 пункт өстәргә:

«10.1) әлеге Нигезләмәнең 14.1 статьясында каралган белешмәләр;»;

18 статьяның 2 өлешендәге 1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1) вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле һөнәри белем дәрәҗәсенә,

муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше, белем һәм күнекмәләр буенча эш стажына, шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата - яллаучы (эш бирүче) вәкиленең муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасын биләү өчен белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә квалификация таләпләренә туры килү таләп ителүе турында карары булганда;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,**
**муниципаль район Советы рәисе** **П.Н. Лоханов**